**ГЛАВА АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

422350,Апас штп. , Совет урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 70 . 19.07.2021

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ законының 37 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2009 елның 9нчы июлендәге 27 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекнең 9 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнне муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан чыгарыла. Муниципаль хезмәткәр вафат булган йә муниципаль хезмәткәр хәбәрсез югалган дип танылган яисә аны закон көченә кергән суд карары белән үлгән дип игълан ителгән очракта, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан үлем (һәлак булу) көннең иртәгесендә яисә суд карарының законлы көченә кергән көнендә төшереп калдырыла.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.В.Нурмиевага йөкләргә.

**Район Башлыгы** **Р.Ф.Хисамутдинов**